**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КОШКИ-НОВОТИМБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
4422383, с.Кошки-Новотимбаево,
ул.Писателей, 16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОШКИ-НОВОТИМБАЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422383 , Кошки-Новотимбаево авылы,
Язучылар ур., 16

тел. (84373) 52-6-31, факс 52-6-31, e-mail: Kntm.Tet@tatar.ru
ОГРН 1061672020365, ИНН/КПП 1638005259/163801001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**12 .11. 2024** **№ 11**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбай авыл җирлеге Башкарма комитетының "Кошки-Новотимбай авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында" 2020 елның 14 апрелендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 15.06.2022 ел, № 1081 карарына ярашлы рәвештә Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбай авыл җирлеге Башкарма комитетының «2020 елда Кошки-Новотимбай авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 14.04.2020 № 5 карары белән расланган Кошки-Новотимбай авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә кертергә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр:

1) 3 пунктта", муниципаль программаларның структур элементларын" сүзләрен төшереп калдырырга.;

2) 12 пунктның икенче абзацында", муниципаль программаларның структур элементларына" сүзләрен төшереп калдырырга.;

3) 12 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"ташламалар алу хокукыннан файдаланган түләүчеләр санының һәм ташламалар куллану өчен потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының яисә түләүчеләрнең гомуми санының 5 еллык чорга нисбәте белән характерлана торган бирелгән ташламаларны түләүчеләрнең ихтыяҗы.";

4) исемендә «2020 елда» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Н.П.Сапожников